Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы

Арча муниципаль берәмлеге

Арча шәһәре

Башкарма комитеты

422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Исполнительный комитет

города Арск

422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

**КАРАР**

24 декабрь 2021 ел №276

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын жыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 25 октябрендәге 51 номерлы Арча шәһәре Советы карары белән 23.11.2021 №1, 23.11.2021 №2, 24.11.2021 №3, 25.11.2021 №4, 25.11.2021 №5 җыеннарда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Арча шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Х. Такташ урамы, 58 йорт, Арча шәһәре, Өрәңге урамы, 4 йорт; Арча шәһәре, Банк урамы, 2А йорты.
3. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Арча шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 152 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймов

Арча шәһәре Башкарма
комитетының
24 декабрь 2021 ел, №276
карарына 1 нче кушымта

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 21 февраленә кадәр «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) 1 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннарда билгеләнгән суммадан 100 (йөз) сум тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7.Түләүләр физик затлар поручениесе буенча почта аша исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша күчерелә.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Арча шәһәре
Башкарма комитетының
24 декабрь 2021 ел, №276
карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________________
Адресы:__________________________________________
___________________________________________________________нигезендә
Сезгә 2022 елның 21 февраленә кадәр төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга ______________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:
РОССИЯ БАНКЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ БҮЛЕГЕ// ТАТАРСТАН БУЕНЧА УФК Казан ш.
Алучы банкы БИК ___019205400
Алучы сч. № 03100643000000011100
Алучы сч. № 40102810445370000079 банк хисабы
ИНН _1609009548
КПП _____160901001
КБК _89511714030 13 0000 150
ОКТМО _92612151
Түләү билгеләнеше- гражданнарның шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары

бер тапкыр түләнә торган түләү кертергә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: _____________________________________________________
______________сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган үзара салымны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына кертү турында ___ номерлы хәбәрне (хәбәрнамә) алдым:

«___» __________ 20__ ел ____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзек корешок тутырыла һәм ______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*